

Ковылкино шәһәренен Спорт сараенда гадәттәгечә, 17нче тапкыр бертуган Куняшевлар призларына мини-футбол буенча турнир узды.
Футбол спортнын ин массакvләм һәм популяр торе булып кала. FIFA-2018 донья чемпионаты ил һәм республикада футбол vсешенә яна этәргеч бирде. Ковылкино районында һәм Мордовиядә танылган футболчылар бертуган *Куняшевлар - Анатолий, Рифат, Рафик, Шәймәрдан һәм Евгений*
- футболга кvп кенә искиткеч спортчылар vстереп, эстафетаны мирас буенча яшь буынга тапшырды: ике туган һәм оч туган кардәшләр, оныклар һәм кvпсанлы нәселдәшләр бирде. Һәр турнирга алар гаиләләре белән килде һәм килә. Яшьләр арасында футболны vстерvдә зур әһәмияткә ия булган Анатолий Куняшев бу турнирны бик кирәкле дип атады. Анын сvзләрен футболистлар династиясенен кечерәк буын вәкилләре дә хуплады. Аларнын авырган чаклары булса да, Ковылкино стадионында vткән «Спартак»нын бер генә уенын да калдырмыйлар.
- Беренче турнир коненнән алып 17 ел эчендә футбол уйный торган тулы бер буын vсеп чыкты. Спорт комитетына, бигрәк *Дмитрий Глушичкинга* рәхмәт! Ул һәрвакыт ярдәм итә. Тренировкаларыбызны vткәрv очен атнага оч тапкыр зал бирә. Безнен максат - футболны пропагандалау. Уенчыларны урамнан сайлыйбыз һәм шулай кvбесен зарарлы гадәтләрдән: алкоголь, тәмәке тарту, наркотиклардан тартып алабыз. Үземә килгәндә, мин жиденче сыйныфтан футбол уйный башладым, хәзер мина 63 яшь. 80нче елларда Мордовия беренчелегендә, Идел буе зонасында унышлы уйнадык. 90нчы елларда Идел буе жинvчеләре булдык. Павловскида чыгыш ясап, Кубаньда кочле халыкара класслы мастерлар командасы белән очрашырга туры килде. Ковылкино «Спартагы» унышларында безнен, бертуган Куняшевларнын казанышы бар, - ди
*Шәймәрдан (Александр) Жарулла улы Куняшев*
. - Хәзер эстафетаны яшь буынга, Ковылкино жыелма командасы очен уйнаган олкән племяннигым Эдуард Курепинга тапшырдык. Мини-футбол буенча һәр турнирга Петербургтан килә ул һәм турнирда катнашучыларга яхшы бvләкләр дә китерә.


СЛОБОДА